**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы**

# КАРАР

**«22» ноябрь 2023 ел** **№ 112**

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән тәртипле һәм нәтиҗәле файдалануны һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2012 елның 27 ноябрендәге 69 номерлы (2018 елның 13 июлендәге 87 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре үз көчен югалтты дип танырга.
3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында https://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы Рәисе Д. А. Ишкинеев